КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 20 апрель г.Казань № 510

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләрен үтәүне туктаткан затка гомерлек файдалануга дәүләт дачасы бирү тәртибен раслау турында» 2006 ел, 2 август, 392 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты» сүзләренә алмаштырырга;

беренче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләрен үтәүне туктаткан затка гомерлек файдалануга дәүләт дачасы бирү тәртибендә:

исемендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өченче зат хокукларыннан азат булган ( хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта

эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт исемлеген булдыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибен раслау турында» 2016 ел, 25 май, 353 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 22 февраль, 114 нче, 2018 ел, 29 сентябрь, 882 нче, 2021 ел, 9 июнь, 443 нче, 2022 ел, 30 декабрь, 1503 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Өченче зат хокукларыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт исемлеген булдыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның «д» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктның «а» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры А.В.Песошин